| СОВЕТ АКЗИГИТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКЪЕГЕТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«12» нче март 2024 ел** **Акъегет** **№153**

Җир эшләрен башкаруга рөхсәт бирү буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Акъегет авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлешенә ярашлы рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Акъегет авыл җирлеге Советы:

1. Җир эшләрен башкаруга рөхсәт бирү буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлегенә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Акъегет авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен тапшырырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Акъегет авыл җирлеге башкарма комитетына Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3.Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру Акъегет авыл җирлеге бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына ел саен бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына башкарыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Акъегет авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча бастырып чыгарырга: Акъегет авылы , Центральная урамы, 4 йорт (авыл җирлеге администрациясе бинасы), шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Акъегет авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе: А. В. Хәйруллина